**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-479 номерлы, 2019 елның 25 ноябрендәге ПУ-707 номерлы һәм 2021 елның 14 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында»;

б) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы турында нигезләмәне» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы турында нигезләмәне» сүзләренә алмаштырырга;

г) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы турында нигезләмәдә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы турында нигезләмә»;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы киңәшмә орган булып тора» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы киңәшмә орган булып тора» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

д) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) составында:

Совет атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы составы»;

Совет составыннан Р.Ш. Ганибаевны, И.Р. Гафуровны, А.С. Кукаркинны, П.Н. Лохановны, М.Н. Садыйковны, Д.И. Фәттаховны, С.Н. Филиппованы, Ж.В. Халтуринаны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Егоров Иван Михайловичны – «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Миңнуллин Марсель Мансур улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Садыйков Ринат Наил улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Сафин Ленар Ринат улын – Казан (Идел буе) федераль университеты ректорын (килешү буенча);

Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Рәисе, Совет рәисе»;

Э.Я. Вафинның – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 16 май
№ 302